ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Олы Кайбыч ав. № 501

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча 2022 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метр бәясе нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында һәм Олы Кайбыч авылында бер квадрат метр торак бина бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган партнерлыгының эксперт-консультация советы («Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022елның 07 февралендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерциясез партнерлыгы хаты) үткәргән тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020-2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның IV кварталына торак сатып алу яки индивидуаль торак йорт төзү өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип табылган яшь гаиләләргә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метр бәясе нормативын 31690 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://kaybici.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Б.Р. Салаховка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров